Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Егоркино авыл җирлегенең Рус Мәнҗәсе авылы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

«20» ноябрь 2020 ел № 7

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2020 елның 20 ноябрендә узган: «2021 елда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Егоркино авыл җирлеге Рус Мәнҗесе авылы территориясендә яшәүче балигъ булган һәр кешедән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Бөек Ватан сугышы катнашучыларының тол калган хатыннарыннан, 1нче төркем инвалидлардан кала, 1000 сум сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә һәм алынган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә ризамы:

Торак пункт чикләрендә юлларны ремонтлау» мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 101 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 61 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 49 кеше тавыш бирде;
«ЮК» позициясе өчен җыенның 12 катнашучысы тавыш бирде
Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Егоркино авыл җирлегенең Рус Мәнҗәсе авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

«2021 елда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Егоркино авыл җирлеге Рус Мәнҗесе авылы территориясендә яшәүче балигъ булган һәр кешедән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Бөек Ватан сугышы катнашучыларының тол калган хатыннарыннан, 1нче төркем инвалидлардан кала, 1000 сум сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә һәм алынган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә ризамы:

Торак пункт чикләрендә юлларны ремонтлау» мәсьәләсе буенча кабул ителгән карарны танырга.

2. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Егоркино авыл җирлегенең Каравыл Тавы авылы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Егоркино авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: А.И.Борисов

Егоркино авыл җирлеге башлыгы А.И.Борисов